

5 сентябрь конне Кадошкино районы Большие Поляны авылында соенечле вакыйга vтте. Исса елгасы аркылы салынган кvпернен тантаналы ачылышы булды.
«Юлдаш» битләрендә тозv эшләре ничек барганы турында танышып килдегез.
Кадошкино районы Большие Поляны авылында Исса елгасы аркылы авыл халкынын зираты, бер урам белән икенче урамны тоташтырган кvпере. Ул кvпер кvптән эштән чыккан иде, ә янасын тозергә финанс кирәк булды.      Авыл халкынын сайланучыларга морәжәгате бушка булмады: Республикабыз бюджетыннан дvрт миллионнан артык сум акча бvлеп бирелгән суммага Тvбән Янашәһәрдән ООО «Мостострой» бригадасы кvперне ясадылар. Озак башкарылган эш кульминацион ноктасына житте. Ниһаять тозv эшләре тәмамланды. Яна кvпер аркылы халык һәм транспорт йори. Куелган план тормышка ашты, сайланучыларга халык наказы vтәлде.
Кvперне тантаналы ачканда районыбыз житәкчесе А.В.Чаткин,  Кадошкино районы депутатлары Советы рәисе В.Н.Кудряшкин, ООО «Мостострой» директоры В.А.Ташкаев, «Единая Россия» партиясенен район бvлеге сәркәтибе Ю.В.Репин һәм жирле халыкнын яше-карты катнашты.
Большие Поляны авылы халкы рәхмәтләрен Мордовия Главасы В.Д.Волковка, Правительство председателе В.Ф.Сушковка, район житәк-челәренә һәм якташларыбыз Камиль Амин улы Мангутов белән Камиль Шәvкәт улы Мангутовка авылнын Почетлы кешесе Ростәм Шакир улы Кильдеев ишеттерде.
Шулай итеп, Большие Поляны халкынын теләге тормышка ашты, кvпер озак хезмәт итсен һәм тынычлы булсын.

**Наилә Долотказина,**
*Большеполяны администрациясе житэкчесе*